Әлмәт Шәһәр Башлыгы
карары

10 октябрь 2019 ел № 31

Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм 46 статьясы нигезендә, Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәрендә гавами тыңлаулар үткәрү турындагы нигезләмә, «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча 2019 елның 10 сентябрендәге 7077 и номерлы комиссия бәяләмәсенә таянып,

КАРАР БИРӘМ:

1. Рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү турындагы карар проекты буенча, Рәсәй Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Гафиатуллин ур., 62 адресы, 16:45:020143:3049 кадастор номерлы җир кишәрлегенә карата җәмәгать тыңлаулары билгеләргә.

- участокның алгы чигеннән минималь чигенүне 3 м дан 1 м га үзгәртергә;

- участокның ян чикләреннән минималь чигенүне 10 м дан 3 м һәм 1 м га үзгәртергә;

- участокның арткы чигеннән минималь чигенүне 20 м дан 17 м га һәм 1 м га үзгәртергә;

- бинаның максималь биеклеген 30 м дан 52 м га үзгәртергә (минус 1 кат - җир асты паркингы);

- участокны төзүнең максималь процентын 23 дән 76 га үзгәртергә;

- урам фронт буйлап минималь киңлекне (йөрү) 48 дән 44 метрга үзгәртергә.

2. Билгеләргә:

2.1. Үткәрү вакыты – 2019 елның 18 октябре 11:00 сәгатьтә.

2.2. Үткәрү сроклары -әлеге карар басылып чыкканнан соң кимендә бер айдан да артык түгел.

2.3. Үткәрү урыны - Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы, Әлмәт шәһәре, Ленин урамы, 39 йорт.

2.4. Рөхсәт ителгән төзелешнең чикле параметрларыннан читкә тайпылуга рөхсәт бирү, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү турындагы мәсьәләсе буенча җәмәгать тыңлауларында катнашуга

тәкъдимнәр һәм искәрмәләр «Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә тапшырылырга тиеш.

Адресы: Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт муниципаль районы,Әлмәт шәһәре, Габдулла Тукай пр-кт, 9а йорты, каб. 6.

2.5. Чыгыш ясау хокукы белән халык алдында тыңлауларда катнашу өчен гариза бирү вакыты 2019 елның 18 октябренә кадәр.

3. «Әлмәт муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» Муниципаль бюджет учреждениесенә (Мордагулова Р. Р.) халык алдында тыңлаулар нәтиҗәләре турында беркетмә һәм бәяләмә үткәрү эшен оештырырга.

4. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

5. Бу карар рәсми бастырылганнан соң үз көченә керә.

6.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзелеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.А.Мөхәммәтҗановка йөкләргә.

Шәһәр Башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.М. Токарев